Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«15» март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 15 мартында узган: Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, вак ташлар сатып алу, юл полотносы профилен үзгәртү өчен хезмәт күрсәтү.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба таш җәю өчен тыгыз нигез салу,
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 214 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 113 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 110 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 3 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, вак ташлар сатып алу, юл полотносы профилен үзгәртү өчен хезмәт күрсәтү.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба таш җәю өчен тыгыз нигез салу,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов